

Киләсе елның беренче гыйнварыннан Россия калдыклар әйләнешенең яңа системасына күчә. Саранскның пресс-үзәгендә каты конкүреш калдыкларын җыю буенча Брифингта Мордовиянең урман, ау хуҗалыклары һәм таби- гатьтән файдалану министры Юрий Васильевич Медянкин белән ООО «Ремондис»ның генераль директоры Светлана Бигессе катнаштылар.
Мордовия чүпләрдән арынуны уңыш-лы алып бара. Санкциясез чүплекләр халыкның һәм табигатьнең саулыгына зыян китерә. Бүген республикабызда каты конкүреш калдыкларын җыю өчен барлыгы 13 мең евроконтейнер урнаштырылган, аның 6,5 мене - районнарда. Калдыкларны санкцияле чүплекләргә ташыйлар.       - Мордовиядә каты конкүреш калдыкларын җыю хезмәте коммуналь өлкәгә күчте, шуңа аны җыю һәм ташу өчен квитанцияне вакытында түләргә кирәк, - ди Юрий Васильевич Медянкин. - Бүген бездәге төсле региональ операторлар Россиянең бары 15 регионында эшли һәм Саранск чүп җыю буенча илебездә - лидер. Регионыбыз районнарында ТБОны җыю буенча проблемалар бар. Халкыбыз чүпне ягарга яки җиргә күмәргә өйрәнгән һәм операторның эшен түләргә ашыкмый. Авылда чүп җыю өчен намуслы түләүче халкыбыз 30-40% артыграк. Вакытында квитанцияннe түлә һәм судка да акчаң китмәс. Беренче гыйнварьдан Россия Федерациясе Законы эшли башлый, без ООО «Ремондис» операторының хезмәтен түләргә бурычлыбыз. Законны бозучыларга җәза каралган: физик затларга - бер мең сумнан икегә кадәр, ә юридикларына - 100 алып 250 мең сум штраф. Россиядә Законны бөтен кеше үтәргә тиеш! Цивилизация алга бара. Безнең табигатьне пычратырга хакыбыз юк; киләсе буынга сакларга тырышырга кирәк.
Шулай ук министр чыгышында Законның үтәлеше артыннан берничә идарә (ведомство) күзәтәчәк - Мордовиянең урман, ау хуҗалыклары һәм табигатьтән файдалану министрлыгы, Мордовия буенча Росприроднадзор, Мордовия буенча Росельхознадзор һәм  муниципаль җитәкчеләр, дигән хәбәрне дә ишеттерде.  Тагы, 2019нче елның беренче гыйнвареннан каты конкүреш калдыкларын җыю өчен (Сарансктан башка) аена бер кешедән индивидуаль йортларда  -  91, 84 сум, ә катлы йортларда – 84, 9 сум, Сарансктагы шәхси йортларда яшәүчеләр – 104, 38 сум түләячәкбез.
Светлана ханым Бигессе аралашканда:
- Киләсе этап – Мордовиянең әлегә кадәр каты калдыкларны җыюны оештырылмаган

авылларда яна системасын кертv һәм каты калдыкларны жыю, эшкәртv структурасынын 2014 елда каты калдыкларны тирән эшкәртv һәм елына 180 тонна альтернатив ягулык булдырган завод тозv белән йомгакланачак, - ди.



Гомумән, чvп жыю беренче карашка гына гади эш кебек, ләкин анын да бик кvп нечкәлекләре бар икән. Мәсәлән, «Призыв» Ләмберә район газетасы еш кына бу проблеманы кvтәреп килә. Анда 15 ел элек ой тирәләре, урманчыклар, кvл-елгалар санкцияләнмәгән чvп урыннарына әйләнгән жирләр турында яза башлап, бvгенге хәлгә кадәр яктырталар. Әле житмәсә, пластик шешәләрнен кешегә китергән зарары турында онытып, бакчаларында яктылар, жиргә кvмделәр, диләр. Чvпне капчыкларда жыю кvп вакытны да ала. Аннан аларны кошлар, этләр-мәчеләр дә тишкәләп туздыра. «Призыв» газета редакциясе халык белән тыгыз эш алып барды, Ләмберә авылы администрациясе һәм Рәшид Ярбек улы Янгибаев житәкчелегендәге «Заря» кооперативы да килеп чыккан мәсьәләне хәл итv буенча кvп коч куйды. Сvз унаеннан, бер батарея, дvрт квадрат метр жирне зарарлый. Искергән люминисцент лампалар, терекомеш термометрлары да әйләнә-тирәгә зур зыян китерә, халык хәзер моны яхшы анлый. Полиэтилен яндыргач – фосген,  поливинилхлорид (ПВХ) – диоксиннар, кеше организмыннан чыгарылмый торган матдәләр бvлеп чыгаралар. Үзләренен коче буенча синильная кислота белән цианистый калийдан кочле. Кончыгыш илләрдә синтетик чvпне ягу кешедә аллергия, астма, рак, авыру балалар туу, генетик потологияләр кебек куркыныч авырулар китерә дигән тикшерv нәтижәләре турында язалар.
Бу эшкә нокта куярга кирәклеге кон кебек ачык иде. Шулай, «Ремондис» компания торкеменен филиалы хезмәте Ләмберә авылы юлларын зур машиналары белән ватмас очен, ой алдындагы евроконтейнерларына капчыкларга тутырылган  чvп-чарны жыеп чыгалар. «Сейчас основная часть населения регулярно выносит ТКО, - ди районда ООО «Ремондис» компаниясе торкеменен филиалы хезмәте житәкчесе С.В. Костюнькин. - Беда в другом: только 20 процентов селян рассчитываются за услуги. На сегодняшний день кампания оказывает услуги по евростандарту и вправе требовать с населения своевременную оплату. Неужели в судебном порядке взыскивать с остальных? А ведь тогда им придется платить и за судебные издержки».
Гадәттә, пенсионерлар ойләренә кертелгән су очен дә, калдыкларны жыйган очен дә тәртипле тvләп киләләр, ә калганнары? Кайбер район авылларында куелган контейнерларны шул сәбәп буенча алдылар. Каты конкvреш калдыклары проблема тудыра. Ә бит уртача, һәр кеше елына бер кубик метр, ягъни 500 килограмм конкvреш калдыгы булдыра.

**Наилә Насырова**